| БАЛТАСИНСКИЙ РАЙОННЫЙ ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ БАЛТАЧ РАЙОН БАШКАРМА КОМИТЕТЫ |
|---|---|

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

«29» 05 2020 г. № 190

**2009 елның 23 апрелендәге 169 номерлы Татарстан Республикасы Балтач район башкарма комитеты карары белән расланган опекага алынучыларны Балтач район башкарма комитеты тарафыннан стационар формада социаль хезмәтләр күрсәтүче социаль хезмәт күрсәтү оешмаларына җибәрү турында карарлар бирү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентына (1 нче кушымта) үзгәрешләр кертү турында**

«Россия Федерациясендә инвалидларны социаль яклау турында» Федераль законга үзгәрешләр кертү һәм «Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында» Федераль законның 7 статьясының 6 өлешенең 16 пунктының үз көчен югалтуын тану хакында» 2009 елның 18 июлендәге 184-ФЗ номерлы Федераль законның 1 статьясындагы 2 пунктының «а» пунктчасы, «Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районында күрсәтелә торган дәүләт хезмәтләре исемлеген раслау турында» 2009 елның 19 апрелендәге 168 номерлы Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы башкарма комитеты карары, «Җирле үзидарә органнары тарафыннан муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең административ регламентларын эшләү һәм раслау тәртибен раслау турында» 2009 елның 12 августындагы 277 номерлы Татарстан Республикасы Балтач район башкарма комитеты карары нигезендә Татарстан Республикасы Балтач район башкарма комитеты **карар бирә:**

1. 2009 елның 23 апрелендә 169 номерлы Татарстан Республикасы Балтач район башкарма комитеты карары белән расланган опекага алынучыларны Балтач район башкарма комитеты тарафыннан стационар формада социаль хезмәтләр күрсәтүче социаль хезмәт күрсәтү оешмаларына җибәрү турында карарлар бирү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентына (1 нче кушымта), 2.5 һәм 2.6 пунктларын түбәндәге редакциядә бәян итеп, үзгәрешләр кертергә:

1.1.

| | | |
|---|---|---|
| 2.5. Хезмәт күрсәтү өчен законнар һәм башка норматив хокукый актлар нигезендә кирәкле документларның | 1. опекунның опекага алынучыны психоневрология тибындагы интернат-йортка стационар социаль хезмәт күрсәтүгә җибәрү турында карар бирү турында гаризасы;<br>2. әлеге учреждениедә торучы һәм махсуслаштырылган учреждениедә стационар социаль хезмәт күрсәтү урынына мохтаҗ булган хокукый сәләтсез затка карата опекун | РФ ГК;<br>РФ ГК;<br>48-ФЗ номерлы Федераль закон;<br>8-ТРЗ номерлы |

| | | |
|---|---|---|
| тулы исемлеге | вазыйфаларын башкаручы сәламәтлек саклау учреждениесе администрациясе гаризасы;<br>3. опека һәм попечительлек билгеләү һәм опекун яки попечитель билгеләү турында норматив хокукый акт яисә опекун таныклыгы;<br>4. үз көченә кергән, гражданны хокукый сәләтсез дип тану турында суд органы карары;<br>5. опекага алынучының паспорт күчермәсе;<br>6. опекага алынучының мөлкәте (автомототранспорт, кыйммәтле кәгазьләр, саклык счетлары һ. б.) турында белешмә;<br>7. затта социаль хезмәт күрсәтү өчен махсус булмаган учреждениедә булу мөмкинлегеннән мәхрүм итүче психик тайпылыш (авыру диагнозы) булу турында мәгълүматны үз эченә алган табиб-психиатрның мәҗбүри катнашуы белән табиб комиссиясе (клиник-эксперт комиссиясе) бәяләмәсе. Бәяләмәдә аның нинди дәвалау-профилактика учреждениесе тарафыннан рәсмиләштерелүе, номеры, рәсмиләштерү датасы, табиб комиссиясе әгъзаларының имзалары, фамилияләре, исемнәре, аталарының исемнәре турында мәгълүмат булырга һәм дәвалау-профилактика учреждениесенең мөһере белән таныкланырга тиеш. | ТР Законы ; 442-ФЗ номерлы Федераль закон; 245 номерлы ТР МК карары |

1.2.

| | | |
|---|---|---|
| 2.6. Дәүләт органнары, җирле үзидарә органнары һәм башка оешмалар карамагында булган хезмәтләр күрсәтү өчен норматив хокукый актлар нигезендә кирәкле документларның тулы исемлеге | - Бердәм дәүләт хокук реестрыннан (Дәүләт теркәве, кадастр һәм картография федераль хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча идарәсеннән) опекага алынучының (хокукый сәләтсез затның) мөлкәте турында мәгълүмат;<br>- балигъ булган опекага алынучының инвалидлык турында белешмәсе (билгеләнгән үрнәктә) һәм медик-социаль экспертиза учреждениесе тарафыннан бирелгән аны реабилитацияләүнең шәхси программасы. | |

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында бастырып чыгарырга һәм Балтач муниципаль районының рәсми сайтында урнаштыру юлы белән халыкка җиткерергә.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Татарстан Республикасы Балтач район башкарма комитетының опека һәм попечительлек секторына йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Балтач район башкарма
комитеты җитәкчесе А.Ф.Хәйретдинов